МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.10.2021 Казан № под-1349/21

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2018 елның 11 октябрендәге под-1488/18 номерлы «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында"

27.07.2004 елның 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законы, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертелүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» карары һәм Татарстан Республикасының 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» законы нигезенә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2018 елның 11 октябрендәге под-1488/18 номерлы «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы

мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) аның вәкаләтле граждан хезмәткәрләре (шул исәптән Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлегеннән һәм граждан хезмәте вакантлы вазыйфасын биләп торуга оештырылучы конкурс үткәрелә торган бүлекчәләреннән (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелүче граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган бүлекчәләр)), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – министр таләбе буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырылучы фәнни, белем бирү һәм кадрлар технологияләре һәм дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре буенча, тиешле өлкәләрдә һәм һөнәри хезмәт эшчәнлегенең төрләрендә белгечләр булып торучы башка оешмалар вәкилләре керә.

Министрлыкның конкурс комиссиясендә бәйсез экспертның гомуми эш вакыты өч елдан артык була алмый. Югарыда әйтелгән срокны исәпләү бәйсез экспертның конкурс комиссиясе составына беренче кертелүеннән гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән срокта бәйсез экспертның Министрлыкның аттестация комиссиясендә булу вакыты исәпләнә.

Әлеге бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына кабат кертү Конкурс комиссиясендә булу срогы тәмамланганнан соң өч елдан да иртәрәк гамәлгә ашырыла алмый.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.»;

2.9. пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Конкурс комиссиясе тарафыннан, аның әгъзасы яки кандидатының сәбәбе (нигезләнеше) күрсәтелгән тәкъдиме буенча видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булганда) утырыш уздыру турында карар кабул ителергә мөмкин.»;

3.4. пунктында:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданның хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);»;

җиденче абзацта «эш (хезмәт)» сүзләрен «хезмәт (эш)» сүләренә алмаштырырга;

4.5.2 пунктының уникенче абзацына «100 балл» сүзләреннән соң «, минималь – 0 балл» сүзләрен өстәргә;

4.5.4 пунктының җиденче абзацына «100 балл» сүзләреннән соң «, минималь – 0 балл» сүзләрен өстәргә;

4.6. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Кандидатның йомгаклау баллы индивидуаль әңгәмә, конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләгән башка конкурс биремнәре, тест нәтиҗәләре һәм башка шундый ук конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган балларның уртача арифметик баллары суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре аларның йомгаклау баллары кимү тәртибендә кандидатлар рейтингын формалаштыра.».

2. Кадрлар сәясәте бүлеге җитәкчесенә (Л.С. Әмирова), боерык кабул ителгән көннән алып 3 эш көне дәвамында аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр в.б. А.М. Әсәдуллина